ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 3-92-40, факс (84366) 3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

**« 12 » май 2025 ел** **№ 14**

**Апаз авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 18 декабрендәге “Апаз авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы “Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы турында” 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында” 138 номерлы карары (29.03.2024 редакциясе), РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Апаз авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 18 декабрендәге “Апаз авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир янсә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла..

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында arsk.tatarstan.ru “Җирлекләр” бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт;  Хәсәншәех авылы, Космонавтлар ур., 20 йорт; Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты; Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Апаз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — Р. Ф.Котдусов